| СОВЕТ МОЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**30 сентябрь 2019 ел.** **Мәлки авылы** **№ 23**

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Мәлки авыл җирлеге
Иске Буа торак пунктында
үзара салым кертү мәсьәләсе буенча
гражданнар җыены билгеләү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге Советына туры китереп, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге карар кабул итте:

1. 2019 елның 10 октябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Буа авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2019 елның 10 октябрендә билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Буа авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:
а) авыл җирлеге территориясен төзекләнләндерү:
- авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;
- агачлар кистерү;
-материаллар сатып алып һәйкәлне төзекләндерү;

в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

г) ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыру, җирләү урыннарын тиешле тәртиптә тоту:

- зиратларны тезекләндерү һәм җирләү урыннарын тиешле тәртиптә чистартып тоту өчен материаллар сатып алу;

« РИЗА» КАРШЫ »

3. Әлеге карарны Мәлки авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Мәлки авыл җирлеге башлыгы: Ф.П.Поляков